**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево
422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевский урамы, 23 нче йорт
Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

2023елның 27 декабре 4122 номер

# КАРАР

**"Лаеш муниципаль районы ихтыяҗлары өчен тәэмин итүчеләрне (подрядчыларны һәм башкаручыларны) билгеләү буенча бердәм комиссия төзү турында" район Башкарма комитеты карарларының үз көчен югалтуларын тану хакында**

"Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында" 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законны үтәү йөзеннән, бюджет һәм бюджеттан тыш чаралардан нәтиҗәле файдалану, намуслы конкуренцияне үстерү, муниципаль ихтыяҗлар өчен заказлар урнаштырганда хәбәрдарлыкны һәм ачыклыкны тәэмин итү максатларында карар бирәм:

1. Үз көчен югалткан дип танырга:
1) «Лаеш муниципаль районы ихтыяҗлары өчен тәэмин итүчеләрне (подрядчыларны һәм башкаручыларны) билгеләү буенча Бердәм комиссия турында нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 26 мартындагы 880 номерлы район Башкарма комитеты карары;
2) «Лаеш муниципаль районы ихтыяҗлары өчен тәэмин итүчеләрне (подрядчыларны һәм башкаручыларны) билгеләү буенча Бердәм комиссия төзү турында» 2020 елның 14 апрелендәге 723 номерлы район Башкарма комитеты карары;
3) «Лаеш муниципаль районы ихтыяҗлары өчен тәэмин итүчеләрне (подрядчыларны һәм башкаручыларны) билгеләү буенча бердәм комиссия төзү турында» 2021 елның 18 февралендәге 384 номерлы район Башкарма комитеты карары.

2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сатып алулар өлкәсендә Бердәм мәгълүмат системасында http://www.zakupki.gov.ru. веб-адрес буенча бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитетының икътисади мәсьәләләр буенча җитәкче урынбасары Л. М. Җамалиевка калдырам.

**Җитәкче** **А.Ә. Нурмөхәммәтов**